ГЛАВА
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**«_18_ »__апрель__ 2019 ел** **№ __51__**

**Арча муниципаль районы башлыгының җәмәгать ярдәмчесе турында**

Яшьләр сәясәтен үстерү процесслары белән нәтиҗәле идарә итү, Арча муниципаль районының жирле үзидарә органнарының, муниципаль учреждениеләрнең дәүләт структуралары һәм җәмәгать оешмалары белән үзара хезмәттәшлеген оештыру максатларында карар бирәм:

1. Арча муниципаль районы башлыгының яшьләр сәясәте мәсьәләләре буенча иҗтимагый ярдәмчесе турында Нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы башлыгы урынбасары Г.Ф.Гариповага йөкләргә.

Муниципаль район башлыгы И.Г. Нуриев

Арча муниципаль районы башлыгының
____________________ел, №__ карары
белән расланды

**Арча муниципаль районы башлыгының яшьләр сәясәте мәсьәләләре буенча җәмәгать ярдәмчесе турында нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә Арча муниципаль районы башлыгының яшьләр сәясәте мәсьәләләре буенча җәмәгать ярдәмчесе (алга таба - җәмәгать ярдәмчесе) эшчәнлеген оештыру хокукый статусын һәм тәртибен билгели.

1.2. Җәмәгать ярдәмчесе Арча муниципаль районы Башлыгына Арча муниципаль районы территориясендә яшьләр сәясәте, җирле үзидарә органнарының, муниципаль учреждениеләрнең дәүләт структуралары, иҗтимагый оешмалар белән үзара хезмәттәшлеге, алып баручы өлкәдә Арча муниципаль районы Башлыгының йөкләмәләрен үтәүне контрольдә тотуны тәэмин итү, яшьләр сәясәте өлкәсендә нәтиҗәле муниципаль идарә итү өчен алып барыла торган оештыру-аналитик эшне тормышка ашыру максатларында билгеләнә.

1.3. Үз эшчәнлегендә җәмәгать ярдәмчесе Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты указлары һәм күрсәтмәләре, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары һәм күрсәтмәләре, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Россия Федерациясенең тармак министрлыклары һәм ведомстволары, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Президенты Указлары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары, "Арча муниципаль районы" муниципаль берәмлеге уставы, муниципаль хокукый актларына таяна.

1.4. Җәмәгать ярдәмчесе Арча муниципаль районы башлыгы вазифасыннан билгеләнә һәм азат ителә. Арча муниципаль районы башлыгына турыдан-туры буйсына һәм үз эшчәнлеге нәтиҗәләре өчен шәхси җаваплылык тота.

1.5. Арча муниципаль районы башлыгы куйган бурычларны һәм функцияләрен гамәлгә ашырганда, җәмәгать ярдәмчесе дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затлары, учреждениеләр һәм оешмалар, иҗтимагый берләшмәләр һәм Арча муниципаль районы халкы белән хезмәттәшлек итә.

1.6. җәмәгать ярдәмчесе үз эшчәнлеген даими нигездә гамәлгә ашыра. җәмәгать ярдәмчесе Арча район Советы аппараты штатына кертелми.

1.7. җәмәгать ярдәмчесенә үрнәк нигезендәге таныклык әлеге Нигезләмәгә кушымта нигезендә бирелә.

## 2. Җәмәгать ярдәмчесенең төп бурычлары һәм функцияләре

2.1. Яшьләр сәясәте мәсьәләләре буенча нәтиҗәле муниципаль идарә өчен шартлар тәэмин итү.

2.2. Арча муниципаль районының җирле үзидарә органнары, муниципаль учреждениеләре белән дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнары арасында Арча муниципаль районындагы яшьләр сәясәте мәсьәләләрен хәл итүдә чаралар һәм үзара хезмәттәшлек ысуллары эшләү.

2.3. Арча муниципаль районы территориясендә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыруны контрольдә тотуда катнашу.

2.4. Арча муниципаль районы башлыгына яшьләр сәясәте мәсьәләләре буенча кабул ителә торган карарларның уңай һәм тискәре нәтиҗәләре турында хәбәр итү.

2.5. Яшьләр сәясәте мәсьәләләре буенча Арча муниципаль районы башлыгының аерым йөкләмәләрен үтәү.

## 3. Җәмәгать ярдәмчесенең вәкаләтләре һәм хокуклары

Үз эшчәнлегендә җәмәгать ярдәмчесе:

3.1. Арча муниципаль район башлыгына яшьләр сәясәте мәсьәләләре буенча муниципаль идарә мәсьәләләре буенча консультатив ярдәм күрсәтә.

3.2. Арча муниципаль районы башлыгы үткәргән киңәшмәләрдә, Арча муниципаль районы башлыгы белән килештереп, башка киңәшмәләрдә һәм чараларда катнаша.

3.3. Яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру кысаларында уздырыла торган чараларда катнаша.

3.4. Җирле үзидарә органнары, муниципаль учреждениеләр җитәкчеләреннән физик культура һәм спорт өлкәсендә кирәкле мәгълүматны соратып ала.

3.5. Арча муниципаль район башлыгы йөкләмәсе буенча үз компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча массакүләм мәгълүмат чараларында чыгыш ясый.

3.6. Аның эшчәнлегенә кагылышлы мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр кертә.

**Арча муниципаль районы башлыгының яшьләр сәясәте мәсьәләләре буенча җәмәгать ярдәмчесе турында нигезләмәгә кушымта**

